ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_04_»___05____2026 ел № 488

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләргә җирләрне кертү турында һәм аларда махсус сакланылучы территорияләр булдыру

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында»гы 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә рәвешен һәм аңа кушып бирелә торган документлар составын раслау хакында»гы 2006 елның 25 октябрендәге 523 санлы карары, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 24.02.2026 № 314/о боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлегенә милек хокукында караган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Абсәләм авыл җирлеге территориясендә урнашкан 16:43:074801:3 мәйданы 4,94 га, 16:43:074901:1 мәйданы 4,13 га, 16:43:074701:1 мәйданы 4,03 га, 16:43:074701:2 мәйданы 1,55 га, 16:43:074601:1 мәйданы 1,55 га булган җир кишәрлекләрен «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр» категориясеннән ял (рекреация) объектларын урнаштыру өчен «Махсус сакланылучы территорияләр һәм объектлар җирләре» җирләре категориясенә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлегенә милек хокукында караган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге территориясендә урнашкан 16:43:074801:3 мәйданы 4,94 га, 16:43:074901:1 мәйданы 4,13 га, 16:43:074701:1 мәйданы 4,03 га, 16:43:074701:2 мәйданы 1,55 га, 16:43:074601:1 мәйданы 1,5 га булган җир кишәрлекләрендә ял (рекреация) объектларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территория булдырырга.

3. Рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территориядән файдалануның махсус хокукый режимын кушымта нигезендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Л.Д. Клинышкова
2-42-19

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы карарына кушымта

04.05.2026 ел № 488

**Җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территориянең махсус хокукый режимы**

1. Гражданнарның ялын, туризмны, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыру өчен билгеләнгән җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территория.

2. Җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территориядә:

2.1 Әлеге территориянең рекреацион билгеләнешенә туры килми торган эшчәнлек тыела, шул исәптән барлык очракларда да тыела:

- махсус сакланылучы территориянең сакланышын бозуга китерә торган эшчәнлек;
- файдалы казылмаларны разведкалау һәм эшкәртү;
- туфрак катламын һәм геологик төзелешне бозуга китерә торган эшчәнлек, җирле үзидарә органнары белән килештермичә генә;
- җирле үзидарә органнары белән килештермичә, гидрологик һәм гидрогеологик режимнарның үзгәрүенә китерә торган эшчәнлек;
- җирле үзидарә органнары белән килештермичә автомобиль юллары, торбаүткәргечләр, электр тапшыру линияләре һәм башка коммуникацияләр төзү;
- гамәлдәге объектларда реставрация эшләреннән тыш, махсус сакланылучы табигать территорияләре эшчәнлегенә бәйле булмаган сәнәгать, хуҗалык һәм башка объектлар төзү;
- махсус сакланылучы территорияләрнең эшләвенә бәйле булмаган механик транспорт чараларының хәрәкәте һәм тукталышы;
- терлекләрне юлдан читкә куу;
- оештырылмаган рекреацион эшчәнлек, автотранспорт тукталышларын урнаштыру;
- билгеләнгән урыннардан һәм мәйданчыклардан читтә учаклар ягу;
- территорияне чүпләү;
- җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру;
- режимны бозуга китерергә мөмкин булган башка эшчәнлек төрләре саклана торган территория.

2.2 Җирле үзидарә органнары белән килештереп ял йортлары, кемпинглар, физик культура һәм спорт объектлары, туристлык базалары, стационар һәм палаткалы туристлык-сәламәтләндерү лагерьлары, балалар туристлык станцияләре, парклар һәм башка шундый ук объектлар төзү рөхсәт ителә.

3. Хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең билгеләнгән режимын үтәү гражданнар һәм юридик затлар өчен мәҗбүри. Җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территориянең билгеләнгән махсус хокукый режимын бозуда гаепле затлар Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә административ, җинаять яисә башка җаваплылыкка тартылалар.